МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.05.2022 Казан ш. № п/111

«Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесен төзү турында» 2010 елның 22 мартындагы 167 номерлы, «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 елның 1 ноябрендәге 997 номерлы карарлары нигезендә һәм «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү максатларында, боерык бирәм:

Кушымтада бирелә торган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләрен расларга.

Министр А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 ел, 5 май, 111/п номерлы боерыгы белән расланды

«Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләре

## I. Хезмәт күрсәтелә торган затларның категорияләре

«Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте (алга таба – бизнес-инкубацияләү хезмәте) күрсәтелә торган затлар булып әлеге Кагыйдәләр нигезендә бизнес-инкубатор резиденты статусы алуга проектлар сайлап алу тәртибе нигезендә бизнес-инкубацияләү хезмәтләреннән файдалану өчен «Ит-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – «ИТ-парк» ДАУ) мөрәҗәгать иткән һәм үзләре белән бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә төзелгән мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә кече эшкуарлык субъектлары тора.

## II. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүнең хокукый нигезе

Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар белән регламентлана:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон;

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәме күрсәтүнең беренче чираттагы чаралары турында» 1996 елның 4 апрелендәге 491 номерлы указы;

Россия Федерациясе Президентының «Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда административ чикләүләрне бетерү буенча кичектергесез чаралар турында» 2008 елның 15 маендагы 797 номерлы указы;

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә шартнамәләрен, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә карата хокуклар күчүен күздә тоткан башка

шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм үзләренә карата әлеге шартнамәләрне төзү конкурслар формасында сатулар уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла ала торган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы боерыгы;

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычына ярдәм күрсәтү» илкүләм проект составына керә торган федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектлары максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешү максатларында Россия Федерациясе субъектларында кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чараларны үтәүгә карата таләпләр һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын оештыручы оешмаларга карата таләпләр раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 125 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милегендә булган мөлкәт өчен аренда түләве күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы милегендә булган мөлкәт өчен аренда түләве буенча ташламалар билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 апрелендәге 218 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 елның 1 ноябрендәге 997 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә һәм дәүләт учреждениеләренә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен раслау турында» 2010 елның 25 маендагы 1364-р номерлы күрсәтмәсе.

## III. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен алу өчен кирәкле документлар исемлеге:

| Шәхси эшкуар | | | |
|---|---|---|---|
| № | Документлар исемлеге | Документлар бирә торган оешма | Бирелгән көненнән башлап документның гамәлдә булу чоры |
| 1. | Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданины шәхесен таныклаучы төп документ турында белешмәләр | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органы | Россия Федерациясе законнары нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Федераль салым хезмәтенең квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрындагы язу кәгазенең күчермәсе | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | Кече эшкуарлык субъектын бетергәнчегә кадәр |
| 3. | Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | 30 календарь көн |
| 4. | Дәүләт теркәвенә алу срогы 3 (өч) айдан артып киткән кече эшкуарлык субъектына, – салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәнең булмавы турында белешмә | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | 30 календарь көн |
| Юридик зат | | | |
| 1. | Федераль салым хезмәтенең квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган гамәлгә кую документларының күчермәсе (үзгәрешләре белән, алар булган очракта) | Кече эшкуарлык субъекты | Кече эшкуарлык субъектын бетергәнчегә кадәр |
| 2. | Федераль салым хезмәтенең квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган Россия оешмасын исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсе, – аның урнашу урыны буенча салым органында | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | Кече эшкуарлык субъектын бетергәнчегә кадәр |
| 3. | Федераль салым хезмәтенең квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазенең күчермәсе | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | Кече эшкуарлык субъектын бетергәнчегә кадәр |
| 4. | Юридик затның башкарма органын билгеләү турында юридик затның башкарма органы имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган карар/беркетмә/боерыкның | Кече эшкуарлык субъекты | Юридик затның башкарма органы билгеләнгәнчегә кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | 30 календарь көн |
| 6 | Дәүләт теркәвенә алу срогы 3 (өч) айдан артып киткән кече эшкуарлык субъектына, – салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәнең булмавы турында белешмә | Федераль салым хезмәте яки аның территориаль органнары | 30 календарь көн |

## IV. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү тәртибенә һәм шартларына карата таләпләр

4.1. Бизнес-инкубацияләү хезмәте «ИТ-парк» ДАУ тарафыннан күрсәтелә. Бизнес-инкубатор «ИТ-парк» ДАУ структур бүлекчәсе булып тора.

4.2. Бизнес-инкубатор хезмәтләрен күрсәтүнең төп бурычы булып мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә торак булмаган бүлмә бирү, шулай ук җитеп бетмәгән интеллектуаль, белем бирү, мәгълүмати, техник, финанс ресурсларын җәлеп итүдә булышлык күрсәтү юлы белән бизнес-инкубатор резидентларына үз проектларын үстерүдә актив ярдәм итү тора.

4.3. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүнең төп максатлары:

мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә конкурентлыкка сәләтле яңа продуктлар һәм хезмәт күрсәтүләр булдыру;

мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә тармакны үстерү кысаларында максатларны аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен максималь уңай шартлар тудыру;

тармакның технологик үсешен тизләтү һәм глобаль базарда бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга дәгъва итүчеләр тарафыннан эшләнелә торган продуктларның һәм чишелешләрнең конкурентлылык сәләтен тәэмин итү;

бизнес-инкубатор резидентлары арасында ачык хезмәттәшлек һәм алар арасында мәгълүмат алмашу өчен мәйданчык булдыру;

Татарстан Республикасы территориясендә аларны гамәлгә ашыру һәм инвестицияләр җәлеп итү өчен, Россия Федерациясенең башка субъектларыннан инновацион проектларны җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру.

4.4. Бизнес-инкубацияләү хезмәте мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын булдыруга, аларга ярдәм итүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

4.5. Бизнес-инкубацияләү хезмәте ике төрле формада күрсәтелә:

турыдан-туры форма бизнес-инкубатор резиденты белән шартнамә гамәлдә булган чорда турыдан-туры бәйләнешләрдән гыйбарәт;

электрон (дистанцион) форма мәгълүмат-коммуникация технологияләре ярдәмендә шартнамә гамәлдә булган чорда бизнес-инкубатор резиденты белән турыдан-туры бәйләнешләрдән гыйбарәт.

4.6. Бизнес-инкубацияләү хезмәтен күрсәтә башлау датасы булып шартнамә төзү датасы санала. Шартнамә шартнамәне озайту мөмкинлеге белән 1 (бер) елга төзелә.

4.7. Бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты 3 (өч) елдан да артмаска тиеш.

4.8. Шартнамәне озайту турындагы карар бизнес-инкубатор җитәкчесенең алга таба хезмәт күрсәтүнең максатка ярашлы булуы турындагы бәяләмәсе нигезендә «ИТ-парк» ДАУ директоры тарафыннан кабул ителә. Бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтелә торган зат белән «ИТ-парк» ДАУ арасында шартнамәне озайту турында каршылыклар килеп туган очракта, пролонгация турында карар әлеге Кагыйдәләргә кушымта булган Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен проектларны сайлап алу тәртибенең 4 пункты нигезендә формалаштырыла торган эксперт советы тарафыннан кабул ителә.

Экспертларны һәм башка компетентлы затларны экспертиза уздыру һәм шартнамәне озайтуның кирәклеге турында бәяләмә бирү өчен җәлеп итү чыгымнары бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бүлеп бирелгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

4.9. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 5.4 пунктында күрсәтелгән җиһазлар белән җиһазландырылган эш киңлеген бирү хезмәте.

Бизнес-инкубаторның электрон (дистанцион) формада бизнес-инкубатор хезмәте алучы резидентларына кирәк булганда эш киңлеге язма гариза буенча бирелергә мөмкин;

б) почта-сәркатип хезмәтләре, аерым алганда: шалтыратулар кабул итү, бизнес-инкубатор резиденты өчен корреспонденция тапшыру; офис техникасы эшләвен тәэмин итү, сөйләшүләр алып бару бүлмәләрен броньлау, эчке чараларны үткәрү зоналары;

в) проект-менеджмент хезмәтләре күрсәтү, ә атап әйткәндә:

проектларны үстерү мәсьәләләрендә тиешле белемгә ия булган квалификацияле белгечләрне җәлеп итеп, белем бирү программасында катнашуны оештыру;

бизнес-инкубатор резиденты проектын үстерү буенча консультация хезмәтләре;

бизнес-инкубаторы резиденты тарафыннан бизнес-планнар һәм юл карталары төзегәндә консультация бирү;

бизнес-инкубатор резиденты белән төркем эшенә һәм (яки) индивидуаль эшкә менторларны, экспертларны һәм башка компетентлы затларны җәлеп итү.

Менторларны, экспертларны һәм башка компетентлы затларны җәлеп итү чыгымнары бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бүлеп бирелгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла;

г) элемтә хезмәтләре күрсәтү, ә атап әйткәндә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә лимитсыз керү хезмәте күрсәтү (файдалана алу тизлеге – секундына 15 Мбит кадәр), һәм түбәндәге характеристикалары булган бер виртуаль серверны бирү:

процессорның такт ешлыгы (CPU) — кимендә 2 ГГц (ике төшле процессор);

оператив хәтер күләме (RAM) – кимендә 4 Гб;

минималь хәтер җыелмасы күләме – 50 Гб;

каналның үткәрү сәләте секундына 1 Мбит булган тышкы бер статистик IP-адрес.

Бизнес-инкубатор резидентларына электрон (дистанцион) формада элемтә хезмәте, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә лимитсыз керү хезмәте күрсәтелә һәм бер виртуаль серверны бирү язма гариза буенча гамәлгә ашырыла;

д) бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бу максатларга бүлеп бирелгән ресурслар чикләрендә А4 яки А3 форматындагы төсле бастырып чыгару хезмәтләре күрсәтү;

е) алдан язылу буенча җиһазландырылган сөйләшүләр алып бару бүлмәләрен бирү;

ж) бизнес-инкубатор биналарын саклау буенча көн саен, тәүлек буе хезмәт күрсәтү;

з) бизнес-инкубатор резиденты эшчәнлеген юридик яктан тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтү, аерым алганда:

документларны рәсмиләштерү буенча консультация хезмәтләре:

Россия Федерациясе территориясендә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (бер юридик заттан да артмаган) рәвешендәге бизнес-инкубатор резиденты юридик затны теркәү өчен, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы юридик зат турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен;

бизнес-инкубатор резидентының физик затын Россия Федерациясе территориясендә шәхси эшкуар буларак теркәү өчен (бер шәхси эшкуардан да артык түгел), Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында торучы шәхси эшкуар турында белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен;

юридик документларны, шул исәптән шартнамәләр, килешүләр, актлар, рәсми хатлар, дәгъва гаризалары һ.б. төзү мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре;

гражданлык, административ законнар һәм авторлык хокуклары мәсьәләләре буенча консультация бирү;

и) бизнес-инкубатор резидентына персоналны сайлау өлкәсендә хезмәт күрсәтү, шулай ук бизнес-инкубатор резиденты вакансияләре турында булган интернет-ресурсларда мәгълүмат урнаштыру;

к) консультация һәм мәгълүмат хезмәтләре күрсәтү, ә атап әйткәндә:

төрле өлкәләрдә компетенция дәрәҗәсен күтәрү максатында бизнес-инкубатор резиденты катнашында махсуслаштырылган чаралар, белем бирү программалары, тренинглар, семинарлар оештыру;

региональ һәм федераль массакүләм мәгълүмат чараларында бизнес-инкубатор резиденты эшчәнлеген мәгълүмати яктырту (максатчан мәгълүмат сәбәпләре булганда);

махсус чараларда, шул исәптән күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, конкурсларда, шулай ук проектны алга этәрү һәм төрле өлкәләрдә бизнес-инкубатор резиденты компетенциясен арттыру максатында башка чараларда катнашуны оештыру. Урыннар саны чикле булган очракта, катнашучыларны сайлап алу бизнес-инкубатор резиденты эшчәнлегенең юнәлешенә, аның проектын үстерүгә, бизнес-инкубатор резиденты хезмәткәрләренең әзерлек дәрәҗәсенә, шулай ук «Ит-парк» ДАУ тарафыннан билгеләнә торган башка критерияләргә бәйле булган максатка ярашканлыкка карап гамәлгә ашырыла.

л) салым салу, бухгалтерлык һәм салым исәбен алып бару мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре күрсәтү;

м) инвесторлар эзләү һәм потенциаль эшлекле партнерлар белән элемтәдә арадашчылык;

н) бизнес-инкубатор резиденты өчен кирәкле мәгълүмат базаларына керү мөмкинлеген бирү;

о) махсуслаштырылган басма продукция сатып алу.

## V. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен матди-техник яктан тәэмин итүгә карата таләпләр

5.1. «ИТ-парк» ДАУ бинalары санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормалар, стандартлар, техник шартлар, башка норматив документлар таләпләренә җавап бирә һәм тиешле сыйфатта бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтә алуны тәэмин итә торган җиһазлар, аппаратура һәм приборлар белән җиһазландырылырга тиеш.

5.2. «ИТ-парк» ДАУ бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнә торган торак булмаган бүлмәләренең гомуми мәйданы 900 кв.метрдан да азрак булмаска тиеш, шул ук вакытта бизнес-инкубатор резидентларын урнаштыру өчен билгеләнгән мәйдан – бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтүгә җәлеп ителгән «ИТ-парк» ДАУ файдалы мәйданының 85 процентган да ким булмаска тиеш.

Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы «ИТ-парк» ДАУ файдалы мәйданы дигәндә бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы торак булмаган бүлмәләрнең гомуми мәйданы турында сүз бара, конструктив һәм функциональ үзенчәлекләр аркасында бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүнең максатчан билгеләнеше нигезендә кулланыла алмый торган подвал, техник һәм башка бүлмәләрдән тыш.

Бизнес-инкубаторның бер резидентына бирелгән торак булмаган бүлмәләрнең мәйданы «ИТ-парк» ДАУ кече эшкуарлык субъектларын урнаштыру өчен билгеләнгән бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнә торган торак булмаган бүлмәләренең 10 процентыннан артмаска тиеш.

5.3. Бизнес-инкубатор резидентының бер хезмәткәренә билгеләнгән мәйдан 4,5 кв. метрдан да ким булмаска тиеш.

5.4. Бизнес-инкубатор резиденты өчен эш урыннары түбәндәге җиһазлар белән җиһазландырыла:

а) офис җиһазлары (өстәл, кресло, стеллажлар, шкафлар, тумба һәм/яки башка кирәкле җиһазларны үз эченә ала) – һәр позиция өчтән дә артык түгел;

б) кыйммәтле әйберләрне саклау өчен шкаф — бер данә;

в) компьютер техникасы (шәхси компьютерлар, клавиатура, компьютер тычканы; автоматлаштырылган эш урыны, ноутбуклар яки планшетлар) язма соратып алу буенча – өч данәдән дә артык түгел;

г) стандарт программа белән тәэмин итү пакеты – бер данәдән дә артык түгел;

д) мультифункциональ җайланма (принтер, сканер, ксерокс) – бер данәдән дә артык түгел.

5.5. Бизнес-инкубатор резидентларына бирелә торган сөйләшү бүлмәсе түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

а) кимендә 30 кв.метр мәйданлы булырга;

б) сөйләшүләр алып бару өчен өстәл һәм урындыклар белән җиһазландырылырга;

в) офис тактасы (флипчарт, магнит-маркер тактасы, интерактив такта һәм/яки башкалар), оргтехника (проектор, автоматлаштырылган эш урыны) белән җиһазландырылган булырга тиеш.

5.6. «ИТ-парк» ДАУ карамагында эчке чаралар үткәрү өчен махсус зона (презентация зонасы) булырга, ул түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

а) мәйданы кимендә 25 кв.метр;

б) видео- һәм фотоматериаллар, микрофон, презентацияләр өчен пульт, офис тактасы, тыңлаучылар өчен утырту урыннары булу.

5.7. Бизнес-инкубатор резидентлары өчен кабул итү бүлмәсендә урнашкан төсле принтерда бастырып чыгару мөмкинлеге булырга тиеш.

Кабул итү бүлмәсе түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: мәйданы 10 кв.метрдан ким булмаска тиеш; ресепшн, офис җиһазлары, оргтехника булырга тиеш.

5.8. «ИТ-парк» ДАУ бизнес-инкубатор резидентлары өчен кирәкле җиһазлар белән әйләндереп алынган, вентиляцияләнә торган ял зонасы (каһвә машинасы, электр чәйнеге, су өчен кулер, кирәк булганда – суыткыч, СВЧ-мич (ризыкны җылыту өчен) һәм азык кабул итү өчен җиһазлар (өстәлләр, урындыклар, кирәк булганда – шкафлар, кәнәфиләр, диваннар) бүлеп бирелергә тиеш.

## VI. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү куркынычсызлыгына карата таләпләр

6.1. Бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтелә торган «ИТ-парк» ДАУ биналары түбәндәгеләргә туры килергә тиеш:

а) янгын куркынычсызлыгы таләпләренә;

б) электр куркынычсызлыгы таләпләренә;

в) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән расланган санитар-эпидемиологик нормаларга.

6.2. Махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратураның эксплуатация документларына ярашлы рәвештә билгеләнеше буенча катгый кулланылырга, техник яктан төзек хәлдә булырга тиеш.

Төзек булмаган махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура алыштырылырга, ремонтланырга (ремонтланырга тиеш булса) яки эксплуатациядән алынырга тиеш.

## VII. Кулланучылар өчен бизнес-инкубацияләү хезмәтләре алу мөмкинлеген тәэмин итә торган таләпләр

7.1. Бизнес-инкубатор резидентының «ИТ-парк» ДАУ бинасына керү мөмкинлеге көн саен, тәүлек әйләнәсе тәэмин ителергә тиеш.

«ИТ-парк» ДАУ эш режимы турында тулы мәгълүмат бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтү турындагы шартнамәдә һәм «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында күрсәтелә.

7.2. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтү кысаларында инвалидларның бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз үтеп керә алуы, шул исәптән объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шулай ук бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү урынына керү максатында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы бизнес-инкубатор резидентлары, шул исәптән инвалидлар өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла.

7.3. Әлеге Кагыйдәләргә кушымта булып торган, мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә бизнес-инкубатор статусы алуга проектларны сайлап алуны үткәрү шартларын һәм тәртибен билгели торган Бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга проектларны сайлап алуга карата тәртип нигезендә конкурс аша сайлап алуны көтмичә генә бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү мөмкинлегенә ихтыяҗ арту күренеше булмавы аркасында, әлеге Кагыйдәләрдә бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү чиратлылыгы билгеләнмәгән.

## VIII. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

8.1. «ИТ-парк» ДАУ штат расписаниесе нигезендә квалификацияле хезмәткәрләр белән комплектланырга тиеш. Персоналны туплау тәртибе «ИТ-парк»ДАУ уставында регламентлана.

8.2. «ИТ-парк» ДАУ хезмәт эшчәнлегенә вазыйфаи күрсәтмәләр нигезендә билгеләнгән квалификация характеристикасы таләпләренә җавап бирә торган белемле затлар кертелә.

8.3. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтә торган «ИТ-парк» ДАУ хезмәткәрләренә бизнес-инкубатор хезмәткәрләре керә.

8.4. Бизнес-инкубатор хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү әлеге вазыйфада биш елга бер тапкыр, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларында, югары

белем бирү оешмаларында һәм тиешле лицензиясе булган башка оешмаларда яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү курсларында уку һәм (яки) стажировка узу юлы белән үткәрелә.

8.5. Бизнес-инкубатор хезмәткәрләренең хокуклары һәм бурычлары «ИТ-парк» ДАУ директоры тарафыннан расланган вазыйфаи күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

8.6. «ИТ-парк» ДАУ хезмәткәрләре «ИТ-парк» ДАУ уставын, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәргә, һөнәри этиканы катгый үтәргә, аларга йөкләнгән, вазыйфаи күрсәтмәләрдә билгеләнә торган вазыйфаларны үтәргә тиеш.

## IX. Бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтелә торган затларны аны алу артыннан мөрәҗәгать иткәндә һәм бизнес-инкубацияләү хезмәтен күрсәтү барышында мәгълүмат белән тәэмин итүгә карата таләпләр

9.1. «ИТ-парк» ДАУ эшчәнлеге, аның Уставы, эчке тәртип кагыйдәләре, Бизнес-инкубатор турында нигезләмә һәм башка документлар белән танышу максатында, «ИТ-парк» ДАУ әлеге документларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштырырга тиеш. Документлар агымдагы датага актуаль булырга тиеш.

9.2. «ИТ-парк» ДАУ, аның дәүләт теркәве, теркәлгән орган исеме турында мәгълүмат шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында урнаштырылган булырга тиеш.

9.3. «ИТ-парк» ДАУ бизнес-инкубатор резидентларына бизнес-инкубацияләү хезмәте турында мәгълүмат бирергә, бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга тиеш. бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат составына түбәндәгеләр кертелгән булырга тиеш:

а) әлеге Кагыйдәләр;

б) бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

в) бизнес-инкубатор резидентларының хезмәт сыйфатына йогынтысы турында мәгълүмат;

г) «ИТ-парк» ДАУ хезмәткәрләре белән бизнес-инкубатор резидентларының коммуникацияләр чаралары турында мәгълүматлар;

д) бизнес-инкубатор резиденты ягыннан бизнес-инкубацияләү хезмәте сыйфатын бәяләү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

е) бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары.

## X. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтүне туктату өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүне туктату өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә шартларын бозу;

б) бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамлану яисә аны вакытыннан алда өзү;

в) бизнес-инкубатор резидентына бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә кысаларында бирелгән мөлкәтне яки «ИТ-парк» ДАУ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне максатсыз куллану.

## XI. Бизнес-инкубацияләү хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең түбәндәге индикаторлары белән тасвирлана:

| Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индика-торның иң чик әһәмияте | Үлчәү коэффи-циенты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә җәлеп ителгән «ИТ-парк» ДАУ персоналының квалификация-сенең бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү таләпләренә туры килүе | процент | (ЧКП/ОЧП)*100, биредә:<br>ЧКП – бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә җәлеп ителгән, таләпләргә туры килә торган «ИТ-парк» ДАУ персоналы саны;<br>ОЧП – бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә җәлеп ителгән «ИТ-парк» ДАУ персоналының гомуми саны | кадрлар бүлеге мәгълү-матлары | 100 | 9 |
| Бизнес-инкубатор резидентларының хезмәт күрсәтүнең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуыннан канәгать булган өлеше | процент | ((Ок+Од)/(2*Вобщ))*100, биредә:<br>Ок – хезмәт күрсәтү сыйфатыннан канәгать булган сораштырылучылар саны;<br>Од – хезмәт күрсәтүнең мөмкин булуыннан канәгать калган сораштырылучылар саны; | бизнес-инкубатор резидент-лары арасында уздырылган анкета нәтиҗәләре буенча хисап | 90 | 8 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Оообщ – сораштырылган гомуми хезмәттән файдаланучыларн саны | | | |
| Бизнес-инкубатор резидентлары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләменә һәм сыйфатына нигезләнгән шикаятьләр булу | берәмлек | абсолют күрсәткеч (бизнес-инкубаторга гражданнардан (оешмалардан) хатлар рәвешендә яисә электрон почта аша килгән шикаятьләрне анализлау һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында белешмәләр нигезендә билгеләнә) | электрон документ-лар әйләнеше | 0 | 9 |
| Инкубацияләнгән, гамәлгә ашыру өлешенә кадәр җиткерелгән (проект эшчәнлегеннән керем ала торган) проектлар өлеше (шул ук вакытта керем күләме әһәмиятле түгел) | процент | Дип = (Инпр/ОК)*100, биредә: Дип – инкубацияләнгән, гамәлгә ашыру өлешенә җиткерелгән проектлар өлеше; Инпр – гамәлгә ашыру өлешенә җиткерелгән, инкубацияләнгән проектлар саны; ОК – инкубацияләнгән проектларның гомуми саны | бизнес-инкубатор резидент-лары арасында уздырылган анкета нәтиҗәләре буенча хисап | кимендә 40 | 8 |
| Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү срогы тәмамланганнан соң бер ел узгач эшли торган инкубацияләнгән проектларның өлеше | процент | Дсмп =Кдюр/Оквп, биредә: ДСМП – инкубацияләнгән, гамәлгә ашыру өлешенә җиткерелгән проектлар өлеше, % Кдюр – хисап датасына Юридик затларның/ Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә буенча гамәлдә | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрын-нан/Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрын-нан өземтә соратып алу нигезендә хисап | 45 | 9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | булган, алдагы елда чыгарылган проектлар саны, данә. Оквп – алдагы елда эшләп чыгарылган проектларның гомуми саны, данә. | | | |

## XII. Шикаятьләрне бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Әлеге Кагыйдәләрне бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) «ИТ-парк» ДАУ язмача кәгазь чыганакта, электрон формада бирелә. «ИТ-парк» ДАУ директоры карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына тапшырыла.

12.2. «ИТ-парк» ДАУ, «ИТ-парк» ДАУ вазыйфаи заты, «ИТ-парк» ДАУ директоры карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, «ИТ-парк» ДАУ һәм Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы рәсми сайтын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук бизнес-инкубатор резидентын шәхсән кабул итү вакытында да кабул ителергә мөмкин.

12.3. «ИТ-парк» ДАУ яисә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына алынган шикаять, аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә, ә «ИТ-парк» ДАУ бизнес-инкубатор резидентыннан документлар кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына, яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозуына карата шикаять биргән очракта, теркәлгән көннән биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.4. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә һәм кабул ителгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында бизнес-инкубатор резидентына язмача һәм аның теләге буенча электрон рәвештә мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

12.5. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта бизнес-инкубатор резидентына бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында «ИТ-парк» ДАУ гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм бизнес-инкубацияләү хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба бизнес-инкубатор резиденты эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, бизнес-инкубатор резидентына җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле

аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән хокук саклау органнарына җибәрә.

12.8. Бизнес-инкубатор резиденты «ИТ-парк» ДАУ вазыйфаи затларының бизнес-инкубацияләү хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

## XIII. Түләүле яки түләүсез нигездә бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында мәгълүмат

13.1. Бизнес-инкубацияләү хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

13.2. «ИТ-парк» ДАУ «ИТ-парк» ДАУ тарафыннан билгеләнгән түләүле хезмәтләрне күрсәтү һәм алар өчен түләү тәртибе һәм шартлары нигезендә бизнес-инкубацияләү хезмәтләре өчен өстәмә түләүле хезмәтләр күрсәтә ала.

«Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кече эшкуарлык субъектларын бизнес-инкубацияләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны төзү, тапшыру һәм карау һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару кагыйдәләренә кушымта

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен
проектларны сайлап алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендә проектларны сайлап алу шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Проектларны сайлап алу елына дүрт тапкырдан да ким булмаган ешлыкта үткәрелә.

3. Проектларны сайлап алу конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла һәм ике этаптан тора:

3.1. Беренче этап читтән торып һәм ябык булып тора, бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга дәгъва кылучыларның гаризаларын караудан тора.

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен проектларны сайлап алуның беренче этабында проект перспективасын түбәндәге критерийларга туры килү-килмәүгә гомуми бәяләү үткәрелә:

| № | Билгесе | Балл |
|---|---|---|
| 1. | Прототибы булу/продуктның минималь нигездә гамәлдә булу сәләте | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |
| 2. | Максатчан аудиторияне тасвирлау | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |
| 3. | Булган проблемалар һәм чишелеш юллары (шул исәптән технология яки продукт хәл итә торган бурычларны тасвирлау/гамәлгә ашырылган проектларның мисаллары) | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |
| 4. | Базар тасвирламасы (күләме, динамикасы, фаразлар, драйверлар, тенденцияләр, конкурентлар) | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |
| 5. | Проектның якындагы өч елда коммерцияләшә алучанлыгы (бизнес-моделе булу, проектның клиентлары булу) | Бизнес-модель булу, проектның клиентлары булу – 3 балл<br>Бизнес-модель булу – 2 балл<br>Бизнес-модель күрсәтелмәгән – 0 балл |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Проект нигезендә мәгълүмат технологияләре (шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) булуы | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |
| 7. | Команда булу яки проектны эшләп бетерү өчен кирәкле компетенцияләрне аңлау | Команда барлык кирәкле компетенцияләргә ия – 3 балл.<br>Команда компетенциясе тулыландыруга мохтаҗ – 2 балл.<br>Кирәкле компетенцияләрне аңлау бар – 1 балл.<br>Команданың компетенцияләре сорау астында – 0 балл. |
| 8. | Конкурентлар һәм конкурентлы чишелешләр/технологияләр һәм продуктлар белән чагыштыру булуы | Әйе – 1 балл<br>Юк – 0 балл |

Сайлап алуның беренче (читтән торып) этабы турыдан-туры этапны үткәрү датасына кадәр 21 эш көне алдан башлана һәм турыдан-туры этапны үткәрү датасына кадәр 10 эш көне алдан тәмамлана. Сайлап алу башлану турында мәгълүмат «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында проектларны сайлап алу башланганчы 15 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла. Сайлап алуның беренче этабын тәмамлау турында мәгълүмат, икенче этапка рөхсәт ителә торган проектларның кушымталы исемлеге белән, проектларны сайлап алуның беренче этабы тәмамланганнан соң, «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында 3 эш көне дәвамында урнаштырыла. Әлеге Тәртип кушымтасы нигезендәге формасы буенча тутырылган гаризалар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җыела. Сайлап алуның беренче этап нәтиҗәләре, проектларны сайлап алуның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында бизнес-инкубатор резиденты статусы алуга дәгъва кылучыларга «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында сайлап алуның беренче этабы бетү турындагы мәгълүмат бастырып чыгарылган көннән соң электрон почта аша 2 эш көне дәвамында хәбәр ителә.

3.2. Икенче этап ачык булып тора, турыдан-туры режимда һәм/яки видеоэлемтә форматында үткәрелә һәм проектларны гавами презентацияләүне үз эченә ала. Икенче этапта претендентка бизнес-инкубатор резиденты статусын бирү һәм аның белән бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә төзүнең максатчанлыгы турында карар кабул ителә.

Бизнес-инкубатор резидентларын электрон (дистанцион) формада сайлап алу процедурасы шундый ук ысул белән башкарыла: видеоэлемтә форматында претендентны халык алдында тәкъдир итү мөмкинлеге белән бизнес-инкубатор резидентларын сайлап алу кысаларында үткәрелә.

Проектларны сайлап алуның икенче этабы нәтиҗәләре турында бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга дәгъва кылучыларга сайлап алу узган проектлар

исемлеген ачык игълан итү юлы белән, проектларны сайлап алуның икенче этабы тәмамланган көнне хәбәр ителә. Шулай ук сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында сайлап алуның турыдан-туры этабы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта урнаштырыла.

4. Проектларны сайлап алу процедурасы экспертлар советы – «ИТ-парк» ДАУ төзегән вакытлы коллегиаль орган тарафыннан бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга дәгъва итүчеләр тарафыннан тәкъдим ителгән проектларны карау, сайлап алу, бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла. Экспертлар советы составына дәүләт хакимияте органнары, фәнни, мәгариф, инвестиция, бизнес-мохит вәкилләре һәм бәйсез экспертлар керә ала. Экспертлар советы составына «ИТ-парк» ДАУ хезмәткәрләре керә алмый. Кирәк булганда, экспертларны җәлеп итү белән бәйле чыгымнарны түләү «ИТ-парк» ДАУ акчалары хисабына башкарыла.

5. Проектларны сайлап алуда катнашу өчен претендент түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

а) әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен электрон рәвештә анкета-гариза;

б) проектны тәкъдир итү (6-15 слайд).

6. «ИТ-парк» ДАУ әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң биш эш көне эчендә мәгълүмат технологияләре ( шул исәптән «үтәли» цифрлы технологияләр) өлкәсендәге проектка башлангыч экспертиза уздыра, кирәк булган очракта – тиешле тармактан эксперт җәлеп итеп.

7. Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен гариза кабул итү әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган документларның тулы булмаган пакетын тапшырган яки аларны тиешенчә рәсмиләштермәгән очракта, шулай ук тәкъдим ителгән проект специализациягә (мәгълүмат технологияләре, шул исәптәп «үтәли» цифрлы технологияләр өлкәсенә) туры килмәгән очракта, гаризаны теркәгән көннән соң биш көнлек чорда инкарь ителә.

8. Башлангыч экспертиза уздырылганнан соң, гариза (электрон форматта) «ИТ-парк» ДАУ эксперт советына бизнес-инкубацияләү хезмәтләрен күрсәтү буенча тәкъдимнәрне карау һәм эшләү өчен җибәрелә.

9. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча 10 көн эчендә бизнес-инкубатор резидентларын сайлап алу беркетмәсе төзелә. Сайлап алу нәтиҗәләре турында беркетмә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтында сайлап алуның турыдан-туры этабы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта урнаштырыла.

10. Бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә сайлап алуны узган претендент белән проектларны сайлап алу тәмамланганнан соң киләсе 45 календарь көн эчендә төзелә.

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен проектларны сайлап алу тәртибенә кушымта

Үрнәк

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен анкета-гариза

| | |
|---|---|
| Проектның исеме | |
| Идеянең/проектның кыскача тасвирламасы | |
| Проектның стадиясе | |
| Инвестицияләр/грантлар (дәүләт һәм шәхси) ӘЙЕ/ЮК | |
| Сайт (булган очракта) | |
| Игълан ителгән проект буенча кече эшкуарлык субъектының тулы исеме* | |
| Гариза бирү максаты | |

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга дәгъва кылучы турында мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| ФИА (булган очракта) | |
| Шәһәр | |
| Элемтә өчен телефоны | |
| E-mail | |

Әлеге документларның эчтәлеге өченче затларга ачылырга мөмкин булуы белән килешәм.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә бизнес-инкубатор резиденты статусын алу өчен проектларны сайлап алу максатларында шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белдерәм.

Әлеге гариза нигезендә, бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга проектларны сайлап алу максатларында, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2021 елның 24 февралендәге 18 номерлы боерыгы белән расланган Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык эчтәлегенә карата таләпләр нигезендә, тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза булуымны белдерәм.

Кушымта: _____ слайдта презентация, 1 нөсхәдә.

«___» ____________ 20___ ел.

* Кече эшкуарлык субъекты сайлап алуда катнашуга гариза биргән очракта